ГЛАВА КАТМЫШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Кирова, д.74, с. Катмыш,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422177

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КАТМЫШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Киров ур., 74 нче йорт, Катмыш авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422177

тел.(факс): (85563) 2-72-03; e-mail: Katmish..Mam@tatar.ru, www: mamadysh.tatarstan.ru

**Карар**
"26" октябрь 2020 ел

**Постановление**
№ 5

Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге Еники Чишмә авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча узган гражданнар җыенында катнашучы затларны теркәү турында

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Катмыш авыл җирлеге " муниципаль берәмлеге Уставы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында" гы 2019 елның 14 октябрендәге 2-48 номерлы Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге Советы карары белән расланган Нигезләмәнең 3.1 пункты нигезендә, КАРАР БИРӘМ:

1.Еники Чишмә авылы фельдшер-акушерлык пункты мөдире Романова Светлана Николаевнаны Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлегенең Еники Чишмә торак пунктында 2020 елның 18 ноябрендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенында катнашучы сайлау хокукына ия булган затларны теркәү өчен җаваплы итеп билгеләргә.

2. Гражданнар җыенында катнашучы затларны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Катмыш авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә теркәүне тәэмин итәргә.

3 Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карар аның басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Катмыш авыл җирлеге башлыгы: И.Г.Габидуллин